**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | ПР-287 24.12.2024 | К А Р А Р

## 2025 елның 1 июленнән 2026 елның 30 июненә кадәр җылылык энергиясенә тарифны раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2025 елга Россия Федерациясе субъектлары буенча уртача коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләменең үзгәрү индексларын һәм 2025-2028 елларга аерым муниципаль берәмлекләр буенча күрсәтелгән индекслар зурлыгыннан рөхсәт ителгән иң чик тайпылышларны раслау турында» 2024 елның 15 ноябрендәге 3287-р номерлы күрсәтмәсе, Татарстан Республикасы Рәисенең "2024-2028 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индекслары турында" 14.12.2023 ел, № 867 Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты эш киңәшмәсенең 06.12.2024 ел, беркетмәсе белән КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 1 июленнән 2026 елның 30 июненә кадәр «Теплосервис» ҖЧҖ кулланучыларына җибәрелә торган җылылык энергиясенә тарифны 1 нче кушымта нигезендә расларга һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карар 2025 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Л.Р. Сираевка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р. Т. Демидов

Актаныш муниципаль
районы Башкарма комитет
җитәкче карарына
1 нче кушымта

от ________2024 ел № ______

Актаныш муниципаль районының "Теплосервис" ҖЧҖ кулланучыларга куела торган җылылык энергиясенә тариф күләме

| Җылылык энергиясенә Тариф (сум/гкал) | | |
|---|---|---|
| № пп | Период | Сумма сумнарда |
| 1 | 01.07.2025 елдан 31.12.2025 елга кадәр | 2553,66 |
| 2 | 01.01.2026 елдан 30.06.2026 елга кадәр | 2553,66 |